КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 июль г.Казань № 582

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә туклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә туклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә туклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү

тәртибенең 2 нче пунктында «2020 елның 23 июненә кадәр» сүзләрен «2020 елның 5 июленә кадәр» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү тәртибенең 2 нче пунктында «2020 елның 23 июненә кадәр» сүзләрен «2020 елның 5 июленә кадәр» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин